**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 24 декабрендәге 5336 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 29 мартындагы 925 номерлы**
**«“Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты” муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләргә хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүне гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитетына бүлеп бирелә торган акчаларны максатчан файдалануны тәэмин итүне аныклау максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 29 мартындагы 925 номерлы «“Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты” муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләргә хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүне гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар атамасын «һәм хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә хуҗалык ихтыяҗлары өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. «Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләргә хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүне һәм хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә хуҗалык ихтыяҗлары өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга»;

1.3. «Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләргә хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүне гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3.1. Тәртипнең атамасын «һәм хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә хуҗалык ихтыяҗлары өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне» сүзләре белән тулыландырырга;

1.3.2. Тәртипнең 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.1. Әлеге тәртип «Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы Казан шәһәренең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә (алга таба – учреждениеләр) Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүне һәм хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә хуҗалык ихтыяҗлары өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру өчен субсидияләр (алга таба – максатчан субсидия, субсидия) бирү күләмен һәм шартларын билгеләү кагыйдәләрен гамәлгә кертә»;

1.3.3. Тәртипнең 2.1 пунктын яңа редакциядә бирергә:

«2.1. Максатчан субсидия алу белән кызыксынган учреждение Казан шәһәренең Физик культура һәм спорт комитетына, максатчан субсидия алу өчен тапшырыла торган документлар исемлеге буенча тапшырылган документлар исемлеген теркәп, әлеге Тәртипнең кушымтасы белән билгеләнгән форма буенча гариза бирә. Тапшырыла торган документлар исемлегенә түбәндәгеләр керә:

- субсидия суммасын исәпләүне һәм нигезләүне, башка мәгълүматны да кертеп, әлеге Тәртипнең 1.1 пункты белән билгеләнгән максатларга бюджет акчаларын бирү кирәклеген нигезләүне үз эченә алган аңлатма язуы;

- түләүләр алучы булып торган физик затларның саны (уртача еллык саны) турында мәгълүмат;

- агымдагы елда яңадан эшкә керешкән, түләүләр алучы булып торган физик затларның саны турында мәгълүмат (хуҗалык ихтыяҗларына бер тапкыр бирелә торган түләүләр өчен);

- учреждениенең әлеге Тәртипнең 2.8 пунктчасы белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документлар;

- субсидия бирү максатына бәйле рәвештә башка мәгълүмат»;

1.3.4. Тәртипнең 2.4 пунктын яңа редакциядә бирергә:

«Максатчан субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C = (N \times M) \times 12 + P \times Me,$$ биредә:

C – хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүне һәм хуҗалык ихтыяҗларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру өчен субсидия суммасы;

N – хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә 2510 сум күләмендә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү;

M – түләүләр алучы булып торган физик затларның саны (уртача еллык саны);

P – хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә хуҗалык ихтыяҗларына 100 000 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү;

Me – спорт әзерлеге юнәлешендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль физкультура-спорт оешмаларында бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр алу хокукына ия хезмәткәрләрнең – яшь белгечләрнең план буенча саны.

Субсидия күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын алучы буларак максатчан субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән Казан шәһәренең Физик культура һәм спорт комитетына тиешле финанс елына һәм план чорына билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә билгеләнә»;

1.3.5. Тәртипнең 2.7 пунктын «, шулай ук хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә хуҗалык ихтыяҗлары өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне» сүзләре белән тулыландырырга;

1.4. Тәртип кушымтасын гамәлдән чыккан дип танырга;

1.5. әлеге карарга кушымтаны Тәртип кушымтасы дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 24 декабрендәге
5336 номерлы карарына
кушымта

«Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль бюджет һәм автоном учреждение тарафыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүне һәм хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә хуҗалык ихтыяҗлары өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру өчен субсидия алуга

ГАРИЗА

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүче | |
| 2 | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| 3 | Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) | |
| 4 | Юридик адрес | |
| 5 | Телефон номеры | |
| 6 | Электрон почта адресы | |
| 7 | Җитәкче | |
| 8 | Субсидия күләме, сумнарда | |
| 9 | Субсидия күчерү өчен реквизитлар | |
| 10 | Субсидия алу мөмкинлеген бирә торган дөрес булмаган белешмәләр тапшырган өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылык каралган булуы турында миңа әлеге гариза белән хәбәр ителде<br>________________<br>(имза) | |
| 11 | Учреждениенең Тәртипнең 2.8 пункты белән каралган таләпләргә туры килүен раслыйм | |
| 12 | Субсидия бирү шартлары белән таныштым һәм Тәртип нигезендә исемлек буенча кирәкле документларны тапшырам | |

Директор ___________________________________________________________________
(имза, фамилия һәм инициаллар)

Гариза бирү датасы: 20____елның «___»__________

____________________